ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 22 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктының «б» пунктчасында «, медицина ягыннан» сүзләрен «яктан» сүзенә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 2 өлешендә «һәм медицина ягыннан» сүзләрен «яктан» сүзенә алмаштырырга;

3) 28 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «, медицина ягыннан» сүзләрен «яктан» сүзенә алмаштырырга;

4) 29 статьяда:

а) исемендә «һәм Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медик-биологик яктан тәэмин итү» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медик-биологик яктан тәэмин итү сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнар һәм физик культура һәм спорт турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $13^2$ һәм $13^3$ пунктлар өстәргә:

«$13^2$) Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медик-биологик яктан тәэмин итүне оештыру;

$13^3$) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яки җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсенең эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү аркасында барлыкка килә торган хәлләрне бәяләүне, әлеге бәяләү критерийларын кертеп, уздыру тәртибен һәм мондый карар кабул итү аркасында барлыкка килә торган хәлләрне бәяләү буенча комиссия төзү һәм күрсәтелгән комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен билгеләү;»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $16^5$ пункт өстәргә:

«$16^5$) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең физик культура һәм спорт өлкәсендә вәкаләтле органы белән килештереп, Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медик-биологик яктан тәэмин итүне оештыру тәртибен раслау;»;

3) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ статья өстәргә:

«$9^1$ статья. **Медицина оешмаларын бетерү, медицина оешмаларының аерымланган бүлекчәләре эшчәнлеген туктату**

1. Медицина оешмалары, Россия Федерациясенең сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнарында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә бетерелә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яки җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсенең эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү мондый карар кабул итү аркасында барлыкка килә торган хәлләрне бәяләү буенча комиссиянең уңай бәяләмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла, комиссия Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан төзелә, һәм аның составына өстенлекле нигездә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы, территориясендә медицина оешмасы яки аның аерымланган бүлекчәсе урнашкан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы,

медицина оешмасын гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы, Федераль законның 76 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән медицина коммерциягә карамаган һөнәри оешмалары һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре керә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы буйсынуындагы, авыл торак пунктында урнашкан бердәнбер медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсенең эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү, күрсәтелгән медицина оешмасын гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан оештырыла торган җәмәгать тыңлаулары (гавами тыңлаулар) нәтиҗәләре буенча билгеләнгән шул авыл торак пункты халкы фикерен исәпкә алып, әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Әлеге өлештә каралган җәмәгать тыңлауларын (гавами тыңлауларны) уздыру һәм аларның нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

4. Җирле үзидарә органы буйсынуындагы, авыл торак пунктында урнашкан бердәнбер медицина оешмасын бетерү, аның аерымланган бүлекчәсенең эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү, күрсәтелгән медицина оешмасын гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан оештырыла торган җәмәгать тыңлаулары (гавами тыңлаулар) нәтиҗәләре буенча билгеләнгән шул авыл торак пункты халкы фикерен исәпкә алып, әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Әлеге өлештә каралган җәмәгать тыңлауларын (гавами тыңлауларны) уздыру һәм аларның нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе медицина оешмасын гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы тарафыннан «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.»;

4) 25 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^2$ пункт өстәргә:

«$6^2$) Татарстан Республикасы спорт җыелма командалары спортчыларын медик-биологик яктан тәэмин итү буенча;».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2018 ел, 11 апрель
№ 16-ТРЗ